**СОВЕТ БИРЮЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422737, РТ, Высокогорский район,
пос. Бирюлинского з/с
ул. Кольцевая, 33

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БӨРЕЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422737, ТР, Биектау районы,
Бөреле җәнлек совхозы пос.
Кольцевая ур., 33

Тел.: 8-84365-76-3-59, Факс: 8-84365-76-5-45, e-mail: Brl.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

от «10 » ноября 2016 ел. № 18

**Бөреле авыл җирлеге Советының «Бөреле авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү, чисталыкны һәм санитар тәртипне тәэмин итү кагыйдәләрен раслау турында»27.05.2015 ел, № 69 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законы нигезендә, Бөреле авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү һәм санитар-эстетик торышын тәэмин итү максатларында, Бөреле авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Бөреле авыл җирлеге Советының 27.05.2015 ел, № 69 карары белән расланган төзекләндерү, чисталык һәм санитар тәртип тәэмин итү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
- 15 бүлектәге 15.2.14 пунктны «җыештыру һәм төзекләндерүнең аерым шартларын» киләсе редакциядә бәян итәргә:
«15.2.14 ял итү урыннарында, кешеләр күпләп була торган пляжларда, скверларда, шулай ук автотранспорт чаралары хәрәкәте:
- транспорт чараларын газоннарда, скверларда, паркларда, пляжларда, моның өчен махсус билгеләнгән урыннардан читтә кую һәм парковкалау;
- кешеләр күпләп була торган урыннарга, мәктәпкәчә һәм гомумбелем бирү учреждениеләренә, Сәламәтлек саклау учреждениеләренә якын урнашкан транспорт чараларын кую урыны, парковка;
- авыл җирлеге урамнарына һәм юлларга машиналар, механизмнар, урамнардан грунт өслекле башка техника алып чыгу;
- гомуми файдаланудагы территориядә озак вакытлы автотранспорт тукталышы.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырып игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru/ муниципаль районнар һәм шәһәр

округлары **http://vysokaya-gora.tatarstan.ru**

3. Бу карар рәсми рәвештә чыгарылганнан соң көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Совет Рәисе,
Бөреле авыл җирлеге башлыгы Т. Х. Баһаветдинов